РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

10.06.2026 № 205/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында иҗтимагый торак комиссиясен төзү турында" 2017 елның 22 июнендәге 264-п номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы территориясендә социаль ипотека программасын гамәлгә ашыру максатларында ( 06.04.2023 ред.), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен раслау турында» 2005 елның 15 апрелендәге 190 номерлы карары белән (25.11.2024 редакциясендә), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында иҗтимагый торак комиссиясен төзү турында" 2017 елның 22 июнендәге 264-п номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1.4.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Башкарма комитет тарафыннан вәкаләт бирелгән вазыйфаи зат социаль ипотека буенча торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гаиләләр реестрын төзи, аны Башкарма комитет җитәкчесе белән раслый законнар нигезендә махсуслаштырылган оешмага (Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт торак фондына) тапшыра.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Р.Шакирҗанов